**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 30 июлендәге 2710 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 30 ноябрендәге 3768 номерлы**
**«Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча**
**муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын**
**раслау турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль закон, 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон, 2025 елның 29 декабрендәге 579-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә виноградчылык һәм шәраб әзерләү эшчәнлеге турында»гы федераль законның 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 30 ноябрендәге 3768 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 18 июнендәге 2550 номерлы, 2025 елның 22 апрелендәге 1272 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында хокуклары теркәлмәгән җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, ачык сервитут билгеләү турында карарның реквизитлары»;

1.2. 2.5.1 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«6) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары (шул исәптән эш документларына кертелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьяның 1.3 өлеше нигезендә мондый документларның бер өлеше булган үзгәрешләрне исәпкә алып) таләпләренә туры килүе турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 5 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару күздә тотылган очракта) бәяләмәсе реквизитлары, дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 статьясында каралган очракларда бирелә торган бәяләмәсе реквизитлары»;

1.3. 2.5.1 пунктның 7 пунктчасында «акт» сүзен «акт реквизитлары» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 9 пунктчасын өстәргә:

«9) әгәр төзелеш авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә, шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләрендә, авыл хуҗалыгы өчен файдалану зоналары, шул исәптән милек хокукында, аренда хокукында яисә башка законлы нигездә шәраб җитештерү хуҗалыкларына яисә виноградчылык хуҗалыкларына караган торак пунктлардагы авыл хуҗалыгы җирләре зоналары составындагы җир кишәрлекләрендә алып барылганда, 2025 елның 27 декабрендәге 468-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә виноградчылык һәм шәраб әзерләү эшчәнлеге турында»гы федераль законның 10 статьясында каралган төзелеш шартларына туры килүен раслау»;

1.5. 2.6.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктчасын өстәргә:

«4) объектны реставрацияләү, консервацияләү, ремонтлау һәм хәзерге вакытта аннан файдалану өчен җайлаштыру очрагында, 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль законда билгеләнгән мәдәни мирас объектларын саклауның тиешле органы тарафыннан расланган мәдәни мирас объектын саклау буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре

җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Башкарма комитет Җитәкчесе**
**вазифаларын башкаручы – беренче урынбасар А.Р.Нигъмәтҗанов**